Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл Советы

КАРАРЫ

15 март 2019 ел № 89

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Баграж-Никольский авыл
җирлеге бюджетыннан башка
бюджетара трансфертлар бирү тәртибе
һәм шартлары турындагы нигезләмә хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.5 статьялары, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ Федераль законның 65 статьясы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегендәге бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып

Баграж-Никольский авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Дальняя Ивановка авылы, Яшьләр урамы, 26 нчы йорт; Баграж-Никольский авылы, Үзәк урам, 31б йорты
территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә,
"Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты, «Интернет" челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Баграж-Никольский авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Баграж-Никольский авыл
җирлеге башлыгы И.В. Ивашкин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль район
Баграж-Никольский авыл Советының
2019 елның 15 мартындагы
№ 89 карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге нигезләмә белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.5 статьялары, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ Федераль законның 65 статьясы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегендәге бюджет процессы турындагы нигезләмә белән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

## 2. Башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары

2.1. Бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджеты (алга таба – җирлек) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджеты (алга таба-Әлмәт муниципаль районы) – 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү, җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне финанс белән тәэмин итү максаты белән муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр нигезендә башкарыла; Россия Федерациясе бюджеты законнары, Татарстан Республикасы бюджеты законнары һәм җирлекнең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очраклардан тыш [1].

[1] Мәсәлән, мондый очраклар сыйфатында муниципаль район, авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләре кысаларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча гамәлгә ашырыла торган өстәмә

2.2. Җирлек бюджетыннан район бюджына башка трансфертлар бирү җирлек бюджетының өстәмә керемнәре хисабына тормышка ашырыла.

2.3. Район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бюджет керемнәре классификациясе нигезендә район керемнәре өлешендә чагылдырыла.

2.4. Башка бюджетара трансфертлар җирлек бюджетыннан район бюджетына бирелә, шул исәптән җирлекнең муниципаль программаларын, ведомство максатчан программаларын гамәлгә ашыру кысаларында да.

2.5. Җирлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен исәпләү район бюджетына әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә башкарыла.

2.6. Башка бюджетара трансфертлар күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты турындагы карарда яисә чираттагы финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү юлы белән һәм җирлек бюджеты чыгымнарының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү юлы белән раслана.

2.7. Башка бюджетара трансфертлар җирлек бюджетыннан район бюджетына чираттагы финанс елына һәм план чорына авыл җирлеге бюджеты турында карар белән расланган сумма чикләрендә һәм җирлек Советы карары нигезендә бирелә.

2.8. Башка бюджетара трансфертлар җирлек бюджетыннан район Советы һәм җирлек Советы карары нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр (2 нче кушымта) нигезендә район бюджетына бирелә.

2.9. Район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү түбәндәге нигезләмәләрдә булырга тиеш:

1) башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

2) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары;

3) башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

4) башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

5) килешүнең гамәлдә булу вакыты;

6) бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартлар үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

7) башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру сроклары һәм тәртибе;

8) килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләре;

9) башка шартлар.

2.10. Килешүләр төзү тәртибе җирлек уставы,
һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2.11. Район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү

---

чараларны финанслау (җирле инициативаларга ярдәм итү), алдан күрелмәгән чыгымнарны, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү һ.б. карала ала.

турындагы килешү проектын әзерләү башка бюджетара трансфертларны күчерүче җирлек бюджеты акчаларын баш бүлүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.12. Район бюджетына башка бюджетара трансфертлар агымдагы елның һәр ай саен 25 числосына кадәр район белән килешү төзегәннән соң бирелә.

2.13.Җирлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар район бюджетының касса үтәлешен гамәлгә ашыручы органда ачылган район бюджетының бердәм счетына акча күчерү юлы белән башкарыла.

2.14. Чираттагы финанс елының 1 январенә файдаланылмаган башка бюджетара трансферт калдыклары буенча операцияләр (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясы 5 пункты нигезендә):

1) агымдагы финанс елының 1 январенә район бюджетыннан күчерелгән һәм максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә җирлек бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

2) җирлек бюджеты акчалары баш администратор тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертларны әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән ихтыяҗлары булу (булмау) турында карар кабул итү, шулай ук аларга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, аларны район бюджетына кире кайтару, әлеге акчалар кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган район бюджеты чыгымнары турындагы хисап нигезендә әлеге бюджетара трансфертлар, расланган тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән форма буенча формалаштырыла һәм тәкъдим ителелә.

3) җирлек бюджетыннан район бюджетына күчерелгән максатчан средстволар, баш администраторының финанс органы белән килештерелгән хисап елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, әлеге бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдәге акчалар агымдагы финанс елында район бюджеты керемена кире кайтарылырга мөмкин.

4) әлеге пунктның 3 пунктчасында каралган карарлар кабул итү тәртибе җирле бюджетлардан башка бюджетара трансфертларны кире кайтару тәртибен җайга сала торган җирле хакимиятнең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.

5) 1 январьгә файдаланылмаган башка бюджетара трансферт калдыклары җирлек бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар җирлек бюджеты керемена Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә алынырга тиеш.

2.15. Башка бюджетара трансфертлар авыл җирлеге бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

- аларны максатсыз куллану ачыкланганда;
- районга тиешле хисап бирелмәгәндә;
- хисапта дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырылганда.

2.16. Районның башка бюджетара трансфертларын ирекле рәвештә кире какмаган очракта, әлеге акчалар җирлек бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

## 3. Башка бюджетара трансфертларны кулланучы контрольдә тоту һәм хисап

3.1. Районның җирле үзидарә органнары җирлек бюджетыннан алынган башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалану һәм алардан файдалану турындагы хисапларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануны җирлек башкарма комитеты контрольдә тота.

3.3. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисап районның финанс - бюджет палатасы тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртип һәм форма буенча тапшырыла.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына муниципаль белем бирү учреждениеләрен карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә Әлмәт муниципаль районы тупланма бюджетының балanслылыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен исәпләү методикасы

1. Әлеге Методика Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына муниципаль белем бирү учреждениеләрен карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә Әлмәт муниципаль районы тупланма бюджетының балanслылыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен исәпләүгә корылган.

2. Бюджеттан башка бюджетара трансфертлар күләме муниципаль мәгариф учреждениеләрен карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетының балanслылыгын тәэмин итү максатларында ел саен бюджет проектын төзегәндә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге вакыт, гомуми ихтыяҗ һәм керем мөмкинлекләре бәяләрендә Баграж-Никольский авыл җирлегендәге аермадан чыгып билгеләнә.

3. Бюджеттан башка бюджетара трансфертлар күләме муниципаль мәгариф учреждениеләрен карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге берләштерелгән бюджетының балanслылыгын тәэмин итү максатларында түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = (Д1 + Д2) – (Р + С),$$

S-җирлек бюджетыннан район бюджетына бирелә торган башка

бюджетара трансфертлар күләме;

Д1 - Россия Федерациясе Бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә формалашкан җирлек керемнәре;

Д2 – җирлек бюджетының тәэмин ителешен тигезләүгә районнан (Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән) дотацияләр;

Р – Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының берләштерелгән бюджетын формалаштыруга бердәм төп якын килү нигезендә формалашкан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җирлек бюджеты чыгымнары;

С - Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә җирлек бюджетыннан Россия Федерациясе субъекты бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына муниципаль белем бирү учреждениеләрен карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә Әлмәт муниципаль районы тупланма бюджетының баланслылыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан бирелә торган бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешүнең ТИПЛАШТЫРЫЛГАН ФОРМАСЫ

«__» _____________ 20___ел № _______________

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Баграж-Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты алга таба «җирлек» дип аталучы, _______________________________________________________________исеме ндә
*(җирлек башкарма хакимияте органы җитәкчесе яисә аларга вәкаләтле затның исеме)*
_____________________________________________________________, гамәлдәге
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булган очракта)* нигезендә _____________________________________________________________________________,
*(башкарма хакимият органы турында нигезләмә, ышаныч кәгазе, боерык яки вәкаләтләрне раслаучы башка документ)* бер яктан, алга таба "Район" дип аталучы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан _____________________________________________________________________________
*(муниципаль хакимиятнең башкарма органы җитәкчесе яисә аның вәкаләтле вәкиле исеме )*
_____________________________________________________________________________,
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булган очракта)*
нигезендә гамәлдә булган___________________________________________________
_____________________________________________________________________________,
*(устав, ышаныч, яки вәкаләтләрне раслаучы башка документ)*
икенче яктан, алга таба Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия

Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, Совет карары нигезендә ике як, Совет карары белән____________________________________________

_______________________________________________________________________

___

*(шәһәр, авыл җирлеге вәкиллекле органы атамасы)*

«___»_______________ № ___ «_______________________________________»,

*(Шәһәр, авыл җирлегенең чираттагы бюджеты турында карар финанс елы һәм план чорына)*

түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр.

## I. Килешү Предметы

1.1. Бюджет чыгымнары классификациясе кодлары буенча авыл җирлеге бюджетының бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) муниципаль мәгариф учреждениеләрен карап тору буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә Әлмәт муниципаль районының берләштерелгән бюджетының балансланууын тәэмин итү максатларында җирлек бюджетыннан 20_ һәм 20_ – 20_ елларда башка бюджетара трансфертны район бюджетына бирү әлеге Килешү предметы булып тора (алга таба – башка бюджетара трансфертлар).):

җирлек бюджеты акчаларын баш бүлүче коды_________________, бүлек _______бүлекчә ____________,

максатчан статья _______________, чыгымнар төре______________.

## II. Районның чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү, аларны үтәү максатында бирелә Башка бюджетара трансфертлар

2.1. Әлеге килешү нигезендә авыл җирлеге бюджетыннан район бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертның гомуми күләме тәшкил итә:

20 _ _ _ елда ____________ (_______________) сум _______ тиен,
*(суммасы язмача)*

20 _ _ _ елда ____________ (_______________) сум _______ тиен,
*(суммасы язмача)*

20 _ _ _ елда ____________ (_______________) сум _______ тиен;
*(суммасы язмача)*

3.1. Башка бюджетара трансфертлар җирлек Советының бюджет турындагы карарында (җирлек бюджетының җыелма бюджет язмасы) каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә._______ (1 пункт 2013 елның 16 октябрендәге №79 - ТРЗ Татарстан Республикасы законы редакциясендә)

3.2. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

а) районда әлеге килешүнең 2.1 пунктында каралган күләмдә, аларны үтәү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре булу;
б) районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле чыгымнарын гамәлгә ашыру;
в) районга башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирү.
г) ______________________________________________________________.

3.3. 1.1 пунктында күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлек бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертны күчерү.Әлеге килешү Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә ай саен 25 числога кадәр, җирлек бюджетының керем өлешен фактта үтәүне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

IV. Якларның үзара хезмәттәшлеге

4.1. Авыл җирлеге түбәндәгеләрне таләп итә:

4.1.1. Район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирелүне әлеге килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү шартлары үтәгәндә, _______ финанс елына һәм план чорына 20_ - 20___ еллар бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә.

4.1.2. Район тарафыннан әлеге килешүдә каралган башка бюджетара трансферт һәм башка йөкләмәләрне бирү шартларын үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру.

4.1.3. Башка бюджетара трансферт бирүне туктаткан очракта, мондый туктатуның сәбәпләре турында районга хәбәр итү.

4.1.4. Әлеге килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча районга әлеге килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә район мөрәҗәгатен алганнан соң 5 эш көне эчендә аңлатмалар җибәрү.

4.1.5.. Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм әлеге килешү белән билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәү:

4.1.5.1. ______________________________________________________________;

4.1.5.2. ______________________________________________________________.

4.2. Авыл җирлеге хокуклы:

4.2.1. Районнан килешүдә каралган башка бюджетара трансферт һәм башка йөкләмәләрне бирү шартларын үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм материалларны, шул исәптән бухгалтерлык исәбе һәм район тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү шартларын үтәүгә бәйле беренчел документларны һәм материалларны соратып алырга.

4.2. 1. Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга:

4.2.1. ______________________________________________________________;

4.2.2. ___________________________________________________________________.

4.3. Район бурычлы:

4.3.1. Әлеге килешүнең 3.2 пунктында билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү шартларын үтәүне тәэмин итә.

4.3.2. Башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмә башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмә җирлек бюджетына кире кайтару турындагы нигезләмәләрне күздә тотса, җирлек бюджетына акчаларны кире кайтару буенча җирлек таләпләрен үтәүне тәэмин итә.

4.3.3. Әлеге килешүгә кушымта нигезендә башка бюджетара трансфертның чыгымнары турындагы хисапларны башка бюджетара трансферт алынган ел өчен киләсе елның 15 гыйнвареннән дә соңга калмыйча бирүне тәэмин итә;;

4.3.4. Соратып алган очракта, районга әлеге килешүдә каралган башка бюджетара трансферт һәм башка йөкләмәләр бирү шартларын, шул исәптән бухгалтерлык исәбе һәм район тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү шартларын үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм материаллар тәкъдим итүне тәэмин итәргә.

4.3.5. Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән срокларда, киләсе хисаптан соң, башка бюджетара трансфертлар акчалары калдыклары өчен киләсе финанс елның 1 гыйнварена кадәр файдаланылмаган җирлек бюджетына кире кайтарырга.

4.3.6. Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм әлеге килешү белән билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә:

4.3.6.1. ___________________________________________________________________;

4.3.6.2. ___________________________________________________________________.

4.4. Район хокуклы:

4.4.1. Әлеге килешү үтәлүгә бәйле рәвештә аңлатмаларны сорап җирлекләргә мөрәҗәгать итәргә.

4.4.2. 1. Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга:

4.4.2.1. ___________________________________________________________________;

4.4.2.2. ___________________________________________________________________

. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Яклар арасында әлеге килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле килеп

туган бәхәсләр, беркетмәләр яки башка документлар рәсмиләштерү белән сөйләшүләр үткәрү юлы белән, алар тарафыннан хәл ителә.Килешмәгән очракта яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.2. Әлеге килешү рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.

Әлеге килешү һәр як исеменнән эш итү хокукына ия булган затлар тарафыннан имзалана һәм яклар тарафыннан әлеге килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәлүгә кадәр гамәлдә була.

Әлеге килешү предметы буенча яңа килешү төзелгән очракта якларның әлеге килешү буенча йөкләмәләре туктатыла.

3.3. Әлеге килешүне үзгәртү яклар инициативасы буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге килешүгә өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.4. Әлеге килешүне ике якның да ризалыгы белән өзәргә мөмкин.

## VII. Якларның түләү реквизитлары:

| Авыл жирлеге исеме | Район исеме |
|---|---|
| Урнашу урыны: | Урнашу урыны: |
| Банк реквизитлары: | Банк реквизитлары: |
| Россия Банкының БИК һәм учреждениесе исеме<br>Исәп-хисап счеты<br>Шәхси исәп<br>Шәхси исәп ачылган Федераль казначылыкның территориаль органы исеме<br>ИНН / КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО | Россия Банкының БИК һәм учреждениесе исеме<br>Исәп-хисап счеты<br>Шәхси исәп<br>Шәхси исәп ачылган Федераль казначылыкның территориаль органы исеме<br>Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре администраторының ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО<br>Район бюджетына кергән башка бюджетара трансфертлар акчалары исәпкә алына торган керемнәрне бюджет классификациясе коды |

## X. Яклар имзалары

| Җирлекнең кыскартылган исеме | Районның кыскартылган исеме |
|---|---|
| ________________ / __________________<br>*(имза)* *(инициаллар, фамилия)* | ________________ / __________________<br>*(имза)* *(инициаллар, фамилия)* |

Татарстан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары турында килешүгә кушымта

Муниципаль белем бирү учреждениеләрен карап тотуга
Әлмәт муниципаль районы бюджеты чыгымнары турында
_______________20__ елына
хисап

Вакытлылык: *еллык*

Үлчәү берәмлеге: *Сум*

| Чыгымнар юнәлеше | каралган акчалар | Фактта хисап датасына кергән | Фактта хисап датасына файдаланылган акча | Хисап датасына калган акчалар |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитет җитәкчесе _____________ ______________
*(имза)*

Финанс-бюджет палатасы рәисе___________ ______________
*(имза)*

Башкаручы__________________________________
*(Ф. И. О., вазифа, бүлекчә)*